РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

24.04.2024 № 7

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы тарафыннан 25.01.2021 елгы №3 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 12.12.2023 елгы № 594-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм Саба районы Прокуратурасының 16.04.2024 елгы №02-08-02-2024/Прдп191-24-20920031 протестын карап, Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 25.01.2021 елгы №3 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 13.4 пунктны "мәгълүмат" сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 25.1 пунктның 11) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта гражданин тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;";

1.3. 25.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 15) пунктча белән тулыландырылырга:

"15) Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән формадагы рөхсәтне рәсмиләштерү.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы

Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/ulbat адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р. Шәмсиев